**МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

11.07.2016 № 393

г.Казань

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2016 елның 25 июлендә теркәлде, № 3442

Үлгән кеше, үлгән көненә, эшкә вакытлыча яраксызлык очрагында һәм ана булуга бәйле рәвештә, мәҗбүри социаль иминиятләштерелергә тиеш булмаган һәм пенсионер булмаган очракларда, шулай ук үле бала йөклелекнең 154 көне үткәннән соң туган очракта, җирләүгә социаль пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 13.07.2015 ел, № 470 боерыгы белән расланган административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Үлгән кеше, үлгән көненә, эшкә вакытлыча яраксызлык очрагында һәм ана булуга бәйле рәвештә, мәҗбүри социаль иминиятләштерелергә тиеш булмаган һәм пенсионер булмаган очракларда, шулай ук үле бала йөклелекнең 154 көне үткәннән соң туган очракта, җирләүгә социаль пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү эшен камилләштерү максатларында **боерык бирәм**:

Үлгән кеше, үлгән көненә, эшкә вакытлыча яраксызлык очрагында һәм ана булуга бәйле рәвештә, мәҗбүри социаль иминиятләштерелергә тиеш булмаган һәм пенсионер булмаган очракларда, шулай ук үле бала йөклелекнең 154 көне үткәннән соң туган очракта, җирләүгә социаль пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының “Үлгән кеше, үлгән көненә, эшкә вакытлыча яраксызлык очрагында һәм ана булуга бәйле рәвештә, мәҗбүри социаль иминиятләштерелергә тиеш булмаган һәм пенсионер булмаган

очракларда, шулай ук үле бала йөклелекнең 154 көне үткәннән соң туган очракта, җирләүгә социаль пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” 13.07.2015 ел, № 470 боерыгы белән расланган административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.3 пунктның 1.3.2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Дәүләт хезмәте турында мәгълүмат алынырга мөмкин:

Үзәк бүлекләрендә урнашкан, хезмәт күрсәтү турында визуаль һәм текстлы мәгълүматтан торган хезмәт күрсәтү турында мәгълүмат стендлары ярдәмендә;

“Интернет” челтәре аша:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының рәсми сайтында: http://mtsz.tatarstan.ru;

Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталыннан (http://uslugi.tatar.ru);

Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан (http://www.gosuslugi.ru);

Үзәк бүлегенә, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына (алга таба – Министрлык) телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яки телефон аша);

Үзәк бүлегенә, Министрлыкка язмача (шул исәптән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать иткәндә.

Мәгълүмат стендларына урнаштырыла торган мәгълүмат дәүләт хезмәте күрсәтү турында бу Регламентның 1.3.1, 1.4, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларында (пунктчаларында) булган белешмәләрне үз эченә ала.”;

2.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| “2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү срогы, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә алып; туктатып тору мөмкинлеге Россия Федерациясе законнары белән күздә тотылган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору срогы | Җирләүгә социаль пособие билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар гариза һәм бу Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар теркәлгән көнне кабул ителә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору Россия Федерациясе законнары белән күздә тотылмаган”; | |

2.15 пунктның “Стандартка карата таләпләр эчтәлеге” графасын түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

“Гариза бирүче гаризаны һәм аңа кушып бирелә торган документларны кәгазьдә шәхсән яисә почта аша тапшыра (җибәрә) ала.

Документларның күчермәләре Россия Федерациясе законнарына туры китереп расланмаган очракта, алар төп нөсхәләрен күрсәтеп тапшырыла һәм Үзәк бүлеге белгече тарафыннан раслана. Үлү турында белешмәнең төп нөсхәсе тапшырыла.

Гариза почта аша җибәрелгәндә, аңа кушып бирелә торган документларның күчермәләре (шәхесне таныклаучы документ күчермәсеннән гайре) Россия Федерациясе законнарына туры китереп расланган булырга тиеш.

Бу вакытта җирләүгә социаль пособие билгеләтү өчен мөрәҗәгать итү көне дип вәкаләтле органның документларны алган көне санала. Документларны җибәрү фактын раслау бурычы гариза бирүче өстендә була.

Дәүләт хезмәте алу өчен гариза бланкын гариза бирүче Үзәк бүлегенә шәхсән мөрәҗәгать итеп алырга мөмкин. Бланкның электрон формасы

Министрлыкның рәсми сайтына урнаштырылган.";

2.16 пункттан "почта аша" сүзләрен төшереп калдырырга;

5.1 пунктның икенче, өченче абзацларында "җитәкче кабул иткән" сүзләрен "җитәкченең" сүзенә алмаштырырга;

5.1 пунктның дүртенче абзацында "министр урынбасары (министр) кабул иткән" сүзләрен "министр урынбасарының (министрның)" сүзенә алмаштырырга.

**Министр в.б.** **М.Р.Гафаров**